Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге
Әбсәләм торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№ 8 «21» ноябрь 2024 ел

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, ире (хатыны), балалары), Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар тыш, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында Пушкин урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (вак ком-таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен шартнамә буенча түләү);
- Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерүгә (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору, (җирләү урыннарын төзекләндерүгә (Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында корыган агач, куакларны кисү; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү))» юлларга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында эләргә.

4.Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева